**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**10 август, 2022 ел** **№ 190**

**Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфалар биләүче затларның, аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 31 мартындагы 47 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының 2016 елның 31 мартындагы 47 номерлы карары белән расланган «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфалар биләүче затларның, аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турындагы нигезләмә»гә (16.05.2022 № 164 карары редакциясендә), «г[O1]» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«г) җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең башка объектын, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлары), цифрлы финанс активларын, цифрлы валюта сатып алу буенча алар хисабына алыш-бирешләр гамәлгә ашырылган (алыш-биреш гамәлгә ашырылган) акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең суммасы (мондый алыш-биреш суммасы) хезмәткәрнең (эшләүченең)

һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елда гомуми керемennән артып китсә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» мәгълүмат сайтында https://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында «https://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе урынбасары,
муниципаль район Башлыгы урынбасары Ә.Ш. Шакиров